СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**31 март, 2022 ел** **№ 156**

**Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына хезмәт хакы түләү һәм акчалата бүләкләүләрне, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары, айлык һәм башка өстәмә түләүләрнең күләмнәрен, һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 25 апрелендәге 220 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 13 декабрендәге 1222 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә һәм социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне тәртипкә салу максатларында, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына хезмәт хакы түләү һәм акчалата бүләкләүләрне, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары, айлык һәм башка өстәмә түләүләрнең күләмнәрен, һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 25 апрелендәге 220 номерлы карарына (2021 елның 12 ноябрендәге №122 карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче кушымтада «(катлаулылык, киеренкелек, хезмәттәге югары казанышлар, махсус эш режимы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 нчы кушымтада «җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын гамәлгә кертүгә бәйле рәвештә җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртеп оештырганда муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәтнең элек биләгән вазыйфасыннан түбәнрәк вазыйфаи окладлы вазыйфасына билгеләгән очрактан тыш, бу вакытта акчалата бүләкләү күләмен исәпләү муниципаль хезмәткәрнең акчалата

күләмен элек биләгән вазыйфасының акчалата түләү күләменә җиткерүне тәэмин итүне исәпкә алып башкарыла)» сүзләрен өстәргә;

7 нче кушымтаны түбәндәге эчтәлекле 3 пункт белән тулыландырырга:

«Муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәтнең ул элек биләгәнгә караганда муниципаль хезмәт вазыйфаларының югарырак төркеменә караган вазыйфасына билгеләгән очракта, аның классылы чин өчен оклады күләмен исәпләү, ул биләгән вазыйфа караган вазыйфалар төркеме өчен беренче классылы чин бирелгәнче, вазыйфаи окладка процентлы ставкадан чыгып, 3 процентка тигез итеп башкарыла.

Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәтнең ул элек биләгәнгә караганда муниципаль хезмәт вазыйфаларының түбәнрәк төркеменә караган вазыйфасына билгеләнгән һәм элегрәк биләгән вазыйфа буенча аңа классылы чин бирелгән очракта, классылы чин өчен оклад күләмен исәпләү вазыйфаи окладка процентлы ставкадан чыгып, 7 процентка тигез итеп башкарыла.»;

10 нчы кушымтаның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төп хезмәт бурычларына юрист яки башкаручы буларак хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм редакцияләү һәм аларга виза салу керә торган, югары юридик белемгә ия булган муниципаль хезмәткәрләргә ай саен түләнә торган түләү (юридик эш өчен өстәмә түләү), түбәндәгеләрдән артмаган күләмнәрдә:

| Муниципаль хезмәт вазыйфалары | Юридик эш өчен өстәмә түләүләр күләме, вазыйфаи окладка процент |
|---|---|
| Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары | 8 |
| Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары | 6 |
| Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары | 4 |
| Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары | 2 |

11 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**Дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлар белән эшләгән өчен ай саен түләнә торган процент өстәмәләре күләменең, һәм муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи оклады күләменең нисбәте**

| Ай саен түләнә торган процент өстәмәләре | (процентларда) |
|---|---|
| «Аеруча мөһим» серлелек дәрәҗәсенә ия булган мәгълүматлар белән эшләгән өчен | 50,0-75,0 |
| «Бөтенләй яшерен» серлелек дәрәҗәсенә ия булган мәгълүматлар белән эшләгән өчен | 30,0-50,0 |
| Рөхсәт рәсмиләштергәндә «яшерен» яшеренлек дәрәҗәсенә ия булган белешмәләр белән эшләгән өчен<br>тикшерү чараларын үткәреп,<br>тикшерү чараларын үткәрмичә | <br><br>10,0-15,0<br>5,0-10,0 |

| | |
|---|---|
| Дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләрдә эш стажы өчен: | |
| 1 елдан 5 елга кадәр | 10,0 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 15,0 |
| 10 ел һәм артыграк | 20,0 |

15 нче кушымтаның 3 пунктында «(катлаулылык, киеренкелек, хезмәттәге югары казанышлар, махсус эш режимы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

15 нче кушымтаны түбәндәге эчтәлекле 7 пункт белән тулыландырырга:

«7) нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен ай саен түләнә торган компенсация түләве, юридик эш өчен өстәмә түләү һәм профильле гыйльми дәрәҗә өчен вазыйфаи окладка ай саен түләнә торган өстәмә түләү – вазыйфаи окладларның 2,5 процентыннан артмаган күләмдә.»;

16 нчы кушымтаның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен ай саен түләнә торган компенсация түләве күләме вазыйфаи окладның 2 процентыннан артмаган күләмдә билгеләнә.»

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Совет рәисе урынбасары,
район Башлыгы урынбасары Ә.Ш. Шакиров